КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 гыйнвар г.Казань № 32

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында» 2017 ел, 27 май, 313 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 24 ноябрь, 1424 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында» 2017 ел, 27 май, 313 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турындагы нигезләмәдә:

1.4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту, милли сәясәт өлкәсендәге башка чараларны муниципаль дәрәҗәдә тормышка ашыру.»;

1.5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы – «Милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту, милли сәясәт өлкәсендәге башка чараларны муниципаль дәрәҗәдә тормышка ашыру» номинациясе буенча.»;

2.11 нче пунктка «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән берлектә» дигән сүзләрдән соң «, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы» дигән сүзләрне өстәргә;

3.1 нче пунктта «һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы» дигән сүзләрне «, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы һәм Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык» дигән сүзләргә алыштырырга;

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле «г» пунктчасын өстәргә:

«г) «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына – «Милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту, милли сәясәт өлкәсендәге башка чараларны муниципаль дәрәҗәдә тормышка ашыру» номинациясе буенча.»;

әлеге карар белән расланган «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын оештыру һәм үткәрү буенча республика комиссиясе составында:

конкурс комиссиясе составыннан Р.Т.Борһановны, Л.Ю.Глухованы, М.З.Шакировны чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Исмәгыйль улы Вәлиевне (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе Марат Һади улы Галиевне (килешү буенча);

«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе, комиссия рәистәше Әгъзам Самат улы Гобәйдуллинны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы юстиция министры Рөстәм Илдус улы Заһидуллинны;

Татарстан Республикасы мәдәният министры Айрат Миңнемулла улы Сибагатуллинны.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                        А.В.Песошин